РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ КОРСАБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422051, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Корсабаш, ул. Школьная, 28
тел. (84362)2-27-49

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КУРСАБАШ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422051, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Курсабаш авылы, Мәктәп урамы, 28 йорт
тел. (84362) 2-27-49

e-mail: korsab.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
23.09.2019

КАРАР
№ 20

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Курсабаш авыл җирлеге Советының
“Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Курсабаш авыл җирлеге Советы
Регламентын раслау турында”гы 30.12.2009 елгы №22
карарына үзгәрешләр кертү турында

ТР Саба районы прокуратурасының 10.09.2019 елгы №02-01-20-19 хатына, Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Уставына туры китереп, Курсабаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының 30.12.2009 елгы №22 карары белән расланган Курсабаш авыл җирлеге Советы Регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 6 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 34.1 статья белән тулыландырырга:

«Статья 34.1.

1. Курсабаш авыл җирлеге башлыгы, район прокуроры, шулай ук Курсабаш авыл җирлеге Уставы, закончалык белән вәкаләтле вазыйфаи затлар, Советның ачык һәм ябык утырышларында катнашырга хокуклы.

2. Советның ачык утырышларында Курсабаш авыл җирлегендә яшәүчеләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

3. Совет тарафыннан аларның эшчәнлегенә караган сорауларны караганда, башкарма комитет эшчеләре ачык утырышларда катнашырга хокуклы.

4. Әгәр гомуми депутатларның күпчелеге тарафыннан хупланса, Совет җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының утырышта катнашуын таләп итәргә хокуклы.

Катнашу турында таләп, утырышка кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, Совет утырышына чакырылучы вазыйфаи затка утырышның көне, вакыты, урыны, утырышка куелган сораулар турында Совет рәисе тарафыннан хәбәр ителергә тиеш.

5. Утырышны ачар алдыннан, Совет рәисе Совет депутатлары булып тормаучы, утырышта катнашучы затлар турында игълан итә.

6. Утырышка чакырылган һәм катнашучы затлар Совет эшенә тыкшынырга хокуклы түгел. (чыгыш ясарга, белдерү эшләргә, хуплау яки ризасызлык белдерергә)

7. Совет карары нигезендә, чакырылганнарга әлеге Регламент кысаларында чыгыш ясау өчен сүз бирелергә мөмкин.”

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан

Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге рәсми сайтында Hhttp://saby.tatarstan.ru/rus/ korsabash адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырырга.

9. Карар рәсми бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Курсабаш авыл җирлеге башлыгы: А.Р. Гыймадиев